НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО




**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН**
**Иске Мөъмин авылы,**
**Әсәкәй районы.**

**(Дәвамы.**
**Башы 6-9 нчы саннарда).**

## Җиденче бүлек

Урманчы да сугыш башлангач та
Тиздән бетмәячәген аңлады.
Кая барып, кемгә бәрелергә
Белмәде ул, эченнән янды.

Шәһәр тирәсен ул урап кайтты.
Анда эвакуация башланган.
Кем өлгергән — киткән. Калганнары
Нәрсә булса-булсын дип, калган.

Хезмәт итеп кайтканына аның
Егерме ел бардыр, мөгаен.
Анда алган белемен кулланырга,
Табар кебек иде ул җаен.

Көнчыгышта хезмәт иткән чакта
Сапер һөнәренә өйрәнгән.
Аннан кайткач, шушы авылның бер
Чибәр кызына өйләнгән.

Өйләнешеп бераз гына торгач
Кызлары да туган аларның.
Хатын үлгән баладан, гомерләре
Кыска булган сөйгән ярының.

Бер ялгызы калгач, өйләнмичә,
Көйләп кенә кызын үстергән.
Кыймагандыр бәлкем, бу авылда
Танышы да булган, йөргән...

Шулай аптырап ай чамасы йөргәч
Кешеләрдән хәбәр ишетте.
Партизаннар монда йөри икән,
Кызга әйтеп, җыенып ул китте...

Төн уртасы, ул урманда йөри
Як-ягына, өскә каранып.
Каршысына берәү килеп чыккач,
Туктап калды кинәт, агарып.

Мылтыгын да алып өлгермәде,
Шул вакытта аны тотып алдылар.
Кулын бәйләп, эндәшмәскә кушып,
Урман эченә тотып салдылар.

Байтак баргач, аклан эчендәге
Бер сарайга алып керделәр.
Сорау алгач шикле түгеллеген,
Кирәк икәнлеген белделәр.

Шушы көннән башлап урманчы да
Поезд шартлатырга йөрегән.
Аны эзләп шәһәр өйләренә
Фоторәсеме дә эленгән.

Кызның егетеннән сәлам алгач
Урман хуҗасы да сөенде.
Ни дисәң дә, әтсеннән башка
Кызга яшәү кыен бит инде.

Урманнарга, кырга карлар яугач
Кайтып килергә дә шикләнде.
Тотулары мөмкин, эз кала бит,
Яз кайтырмын әле, диде.

Сугыш башланганга икенче ел.
Кыш та үтеп китте сизелми.
Немец фашистлары явызлашты,
Кем күрмәгән аны, шул белми.

Шуңа карамастан, көне-төне
Фашистларга тынгы булмады.
Кайда эшелоннар тәгәрәде,
Кайда казармалары янды.

Авыл халкын партизанга ярдәм
Итәсез, дип гаепләделәр.
Кызның әтисен дә шушы арада
Кайтып китәчәген белделәр.

Авыл кешеләре арасында
Сатлыклар да булган, күрәсең.
Облава да ясап караганнар
Тотар өчен шунда берәрсен.

Шулай беркөн төнлә егет белән,
Кыз янына кайтып килмәкче
Булды әти. Тик белмәде шул
Күрше-тирәсендә барын әләкче.

Командирларыннан рөхсәт алгач,
Егет белән юлга чыктылар.
Ай калыккан, урман шундый матур,
Сокланып туя алмый болар.

Менә авыл, этләр генә өрә,
Кеше йөрегәне күренми.
Өй янында, сарай тирәсендә
Саклап торганнары беленми.

Хуҗа егетне калдырып, әкрен генә
Өй янына ук килде.
Артка карамыйча, тәвәккәлләп,
Тәрәзәгә барып иелде.

Шул минутта күреп өлгермәде,
Ике кулыннан да тоттылар.
Мылтык белән бәреп урманчыны,
Йөзе белән җиргә ектылар.

Ишек алдындагы бу тавышка
Йокысыннан кызы уянды.
Ут кабызып чыккач, җирдә яткан
Әтекәсен күреп хуш калды.

Ул арада машина да килде.
Урманчыны шунда салдылар.
Полицайлар моңа куанышып
Бер-берсенең кулына суктылар.

Шунда кызы, мескен, әтисенә
Бер сүзен дә әйтә алмады.
Өйгә кереп сәкесенә ятып
Үкси, үкси кызый елады.

Урманчыдан каты сорау алгач
Шәһәр төрмәсенә яптылар.
Бер-ике ай үткәч, таң алдыннан
Шәһәр читенә чыгып аттылар.

Аның турында кызы белмәде дә.
Кешеләрдән генә ишетте.
Кайгысыннан шул фашистлардан
Үч алырга ул ант итте.

**(Ахыры киләсе санда).**

ЯҢАЛЫКЛАР

# ИҢЕГЕЗГӘ — ЗӘҢГӘР ШӘЛ...

Төзекләндерелгәннән соң ачылган К.Тинчурин ис. Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында танылган сәнгатькәрләребезнең иҗат кичәләре башланып китте. 17 нче май кичендә биредә танылган шагыйрә, балалар язучысы, популяр җырлар авторы, ТР атказанган сәнгать эшлеклесе Резеда Вәлиеваның түгәрәк юбилеена багышланган «Рәхмәт сиңа, язмыш» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды. Зәвык белән эшләнгән тамаша залы шагыйрәнең иҗатын хөрмәт итүче, яратучылар белән тулы иде.

Кичәнең режессеры Нурания Җамали, алып баручысы Инсаф Абдулла вакыт ягыннан бик тар кысаларда хәрәкәт иттәргә мәҗбүр булдылар. Резеда Вәлиеваның иҗатын тулырак ачып бирү максатыннан балаларга атап язылган композицияләрне дә, шагыйрәнең лирик әсәрләренә иҗат ителгән җырларны да, күпсанлы котлауларны да, үзенчәлекле шигърияten дә кыска гына вакыт аралыгында ачып бирергә кирәк иде. Гомумән алганда, әлеге иҗат әһелләре бу максатларга ирештеләр дип әйтеп була.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Ирада Әюпова Р.Вәлиевага Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән Мактау хатын тапшырды. ТР язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов исә шагыйрәнең Шәүкәт Галиев, Хакимҗан Халиков кебек танылган балалар язучыларының традицияләрен дәвам иттерүен, әдәбиятыбызда, мәдәниятебездә күпсанлы җырлар, үзенчәлекле лирик шигырьләр авторы буларак үзенең лаеклы урынын алган шәхес булуын билгеләп үтте. Кичәдә чыгыш ясаган Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе урынбасары, язучы, шагыйрь Дамир Гыйсметдинов: «Татар дөньясы Сезне белә, хөрмәт итә һәм ярата. Сабыйлардан алып агайларга хәтле, Себерләрдән алып Кытайларга хәтле. Сез татар җанына онытылмас җырларыгыз, беркемне дә битараф калдырмый торган шигырьләрегез, күркәм холкыгыз белән үтеп кердегез,» — диде. Конгрессның Рәхмәт хатын бүләк итеп, Д. Гыйсметдинов дулкынланган шагыйрәнең иңнәренә матур милли зәңгәр шәл салды. Зал бу котлауларны алкышлап кабул итте.

Кичәдә Резеда Вәлиева белән беррәттән танылган композиторлар Зөфәр Хәйретдинов, Фәрит Хатыйпов, җырчылардан Флера Сөләйманова, Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар, Зәйнәп Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов һ.б. бар иде.

Әйтергә кирәк, тамашачылар арасында Казаннан, Татарстаннан гына түгел, Оренбург, Ульян, Самара һәм башка өлкәләрдән килгән шагыйрәнең талантын үз итүчеләр шактый иде.

Безнең белешмә. Резеда Вәлиева 1930 нчы елның 1 нче маенда дөньяга килә. 1952 нче елда Казан дәүләт университеты тәмамлаганнан соң, Татар китап нәшриятының балалар әдәбияты бүлеге мөхәррире булып эшли. 1950 нче елларда — яза, 1960 нчы елларда шигырьләрен бастыра башлый. Бүгенге көндә аның 40ка якын шигырьләр, поэмалар, әкиятләр, табышмаклар җыентыгы билгеле. Аның иҗатында табигатькә, туган якка мәхәббәт, эчкерсез саф хисләр ачыла. Р.Вәлиева — күпсанлы җырлар авторы. Ул шулай ук рус балалар поэзиясен татар теленә тәрҗемә итеп укучыларга җиткерүче шагыйрә буларак та танылды.

**(Из сайта ВКТ)**

**Резеда ВАЛИЕВА частый гость Оренбуржья. Особенно полюбились ей Асекеевцы. Здесь ее принимают как родную, интересуются ее творчеством. Мы присоединяемся к поздравлениям и желаем ей здоровья, счастья, дальнейших творческих успехов.**

**«Туган як» — газета твоего родного края!**

**ПРОДОЛЖАЕТСЯ ПОДПИСКА на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край» на второе полугодие 2010 года.**

Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.

**Подписаться можно в любом почтовом отделении** или непосредственно у почтальонов.

**ИНДЕКС ИЗДАНИЯ 53167. ЦЕНА ЗА ПОЛУГОДИЕ — 94 РУБЛЯ 50 КОПЕЕК.**

**Справочные телефоны в Асекеево: 8-(353-51) 2-22-81 или 8-932530733.**